| СОВЕТ<br>Красноборского сельского поселения<br>Агрызского муниципального района<br>Республики Татарстан | Татарстан Республикасы<br>Әгерҗе муниципаль районы<br>Красный Бор авыл җирлеге<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25.12.2025 с .Красный Бор № 7-2

Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлеге Советының 2024 елның 2июлендә кабул ителгән 43-1 номерлы «Җирле салым суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең үз көчләрен югалткан закон актлары (закон актларының аерым нигезләмәләре) дип тану турында»гы 2025елның 28 ноябрендә кабул ителгән 425-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Красный Бор авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлеге Советының 2024елның 2 июлендә кабул ителгән 43-1 номерлы « «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
   1.1. 1 нче пунктның 1 нче абзацын түбәндәге редакциядә язып чыгарырга: «1) Россия Федерациясенең гражданлык процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә физик затның үлгән яки үлгән дип игълан ителгән көненнән өч еллык срокның үтеп китүе (законнарда каралган очраклардан тыш) һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 59 нчы маддәсенең 1 нче пунктының 3 нче абзацында билгеләнгән очракларда;»

   1.2. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы Федераль закон», Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында «2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән» сүзләрен карар преамбуласыннан төшереп калдырырга.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

3. Бу карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча интернеттагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырырга һәм Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталы кысаларында, https://agryz.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга, шулай ук Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлеге җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында игълан итәргә.
4. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Е.А. Яковлева